Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ | КАРАР

Менделеевск ш.

06.04.2026 ел | № 43

Мөлкәтне федераль милеккә тапшыру турында

«Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы, «Мөлкәтне федераль милектән Россия Федерациясе субъекты милкенә яки муниципаль милеккә, Россия Федерациясе субъекты милкеннән федераль милеккә яки муниципаль милеккә, муниципаль милектән федераль милеккә яисә Россия Федерациясе субъекты милкенә тапшыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге турында» РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 13 июнендәге 374 нче номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 41869 нчы хәрби часть командиры үтенечнамәсен һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 13637 нче хәрби часть командиры үтенечнамәсен карап, шулай ук махсус хәрби операция уздыру зонасында бурычларны үтәү өчен махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм чаралары күрсәтү максатларында,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының җирле үзидарә органына түбәндәге муниципаль мөлкәтне Россия Федерациясе Оборона министрлыгының федераль милкенә тапшыруны йөкләргә:

1.1. 41869 нчы хәрби частенә:

- УАЗ 220694 автомобиле шасси 431799, дәүләт номеры М511ТВ 116 RUS, 295000,00 сумга.

- CHEVROLET NIVA автомобиле, VIN X9L212300C0433820, дәүләт номеры Р 341 МЕ 116 RUS, 498500,00 сумга, калдык бәясе 116296,31 сум.

1.2. 13637 нче хәрби частьенә:

- Шевроле Нива автомобиле, VIN X9L212300J0644143, дәүләт номеры А 439 ОУ 716 RUS, 572815,00 сумга;

- ашыгыч медицина ярдәме автомобиле Форд Транзит дәүләт номеры С 936 НН 116RUS, 2012 елгы чыгарылыш, VIN XUS22270GC0000581, 1746900,00 сумга.

2. Менделеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына муниципаль мөлкәтне федераль милеккә тапшырганчы Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 41869 һәм 13637 хәрби часте белән муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану турында шартнамә төзүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. https://mendeleevsk.tatarstan.ru .

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын саклау буенча даими комитетына йөкләргә.

Рәис урынбасары Л.К. Галеева